КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 28 гыйнвар г.Казань № 31

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль учреждениеләре күрсәтә торган дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләрне планлаштыру һәм мониторинглау буенча мәгълүмат ресурсын формалаштыруның бердәм ведомствоара системасы турында» 2012 ел, 20 октябрь, 890 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль оешмалары күрсәтә торган дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләрне планлаштыру һәм мониторинглау буенча мәгълүмат ресурсын формалаштыруның бердәм ведомствоара системасында урнаштырыла торган дәүләт оешмалары, муниципаль оешмалар, шулай ук муниципаль берәмлекләрнең тышкы төзекләндерү объектлары тасвирнамәләрен мониторинглау һәм аларның алып барылышын тәэмин итү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль учреждениеләре күрсәтә торган дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләрне планлаштыру һәм мониторинглау буенча мәгълүмат ресурсын формалаштыруның бердәм ведомствоара системасы турында» 2012 ел, 20 октябрь, 890 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабине-

тының 2013 ел, 30 май, 361 нче; 2013 ел, 30 сентябрь, 701 нче; 2016 ел, 26 гыйнвар, 41 нче; 2018 ел, 22 гыйнвар, 26 нчы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль оешмалары күрсәтә торган дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләрне планлаштыру һәм мониторинглау буенча мәгълүмат ресурсын формалаштыруның бердәм ведомствоара системасында урнаштырыла торган дәүләт оешмалары һәм муниципаль оешмалар, шулай ук муниципаль берәмлекләрнең тышкы төзекләндерү объектлары тасвирнамәләрен мониторинглау һәм аларның алып барылышын тәэмин итү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

исемендә «дәүләт оешмалары һәм муниципаль оешмалар» сүзләрен «дәүләт оешмалары, муниципаль оешмалар» сүзләренә алмаштырырга;

2 бүлекнең 2.1 пунктына түбәндәге абзацны өстәргә:

«Яңа төзелгән оешманы (аерымланган структур бүлекчәне) гамәлгә куючы түбәндәге документлар исемлеген билгеләнгән тәртиптә өстәмә рәвештә җибәрә:

күчемсез мөлкәт объектының техник паспорты күчермәсен;

әлеге мөлкәтнең беренчел-торгызу кыйммәтен үз эченә алган кабул итү-тапшыру акты белән мөлкәтне дәүләт (муниципаль) милеккә тапшыру турындагы карар күчермәсен;

дәүләт (муниципаль) мөлкәтен дәүләт (муниципаль) учреждениесенә беркетү турындагы шартнамә күчермәсен (булган очракта).»;

әлеге Нигезләмәгә теркәлгән 1, 4 нче кушымтаны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә;

әлеге Нигезләмәгә теркәлгән 2 нче кушымтаның 8 нче таблицасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8 нче таблица. Яшьләр сәясәте оешмаларының типлары һәм төрләре

| Оешманың тибы | Оешманың төре |
|---|---|
| 1 | 2 |
| Ял итү оешмасы | яшьләр үзәге |
| | яшәү урыны буенча яшьләр (үсмерләр) клубы |
| Социаль хезмәт күрсәтү оешмасы | балаларга һәм яшьләргә психологик-педагогик ярдәм күрсәтү үзәге |
| | балалар һәм яшьләр өчен телефон аша ашыгыч психологик ярдәм күрсәтү үзәге |
| Савыктыру-ял итү оешмасы (лагерь) | савыктыру-ял итү учреждениесе (лагерь) |
| Бертип булмаган оешмалар | балалар һәм яшүсмерләр ялын, аларны савыктыруны һәм эш белән тәэмин итүне оештыру үзәге |
| | җәмәгать тәртибен саклау буенча яшьләр (студентлар) формированиеләре үзәге |

| 1 | 2 |
|---|---|
| | студентларның хезмәт отрядлары үзәге |
| | республика яшьләр, инновация һәм профилактика программалары үзәге |
| | яшьләргә булышлык күрсәтү үзәге |
| | хәрби-патриотик эшләр һәм хәрби хезмәткә әзерләп бетерү үзәге». |

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль оешмалары күрсәтә торган дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләрне планлаштыру һәм мониторинглау буенча мәгълүмат ресурсын формалаштыруның бердәм ведомствоара системасында урнаштырыла торган дәүләт оешмалары һәм муниципаль оешмалар, шулай ук муниципаль берәмлекләрнең тышкы төзекләндерү объектлары тасвирнамәләрен мониторинглау һәм аларның алып барылышын тәэмин итү тәртибе турындагы нигезләмәгә 1 нче кушымта

Яңа төзелгән, үзгәртеп оештырылган, шулай ук тибын үзгәртү юлы белән төзелгән дәүләт оешмасы һәм муниципаль оешма (аерымланган структур бүлекчә) турында гомуми мәгълүматлар

Муниципаль район, шәһәр округы исеме ________________________________

____________________________________________________________________________

Оешманың – юридик затның тулы исеме ________________________________

____________________________________________________________________________

Оешманың – юридик затның аерымланган структур бүлекчәсенең тулы исеме [1]

____________________________________________________________________________

____________________________________________________________________________

| Т/с | Реквизитның исеме | Реквизитның әһәмияте |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1. | Эшчәнлек төре[2] | |
| 2. | Ведомствога каравы[3] | |

[1]Юридик затның аерымланган структур бүлекчәсе турындагы гомуми мәгълүматларны рәсмиләштергәндә тутырыла.

[2]Мәгариф, сәламәтлек саклау, мәдәният, социаль хезмәт күрсәтү, яшьләр сәясәте, физкультура һәм спорт, бертип булмаган.

[3]Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы, Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы, Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы, Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы, Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы, Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы, Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы, Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе, Татарстан Республикасының Этил спирты, алкогольле продукция җитештерүне, әйләнештә йөртүне һәм аларның сыйфатын дәүләт тикшерүендә тотуны тәэмин итү һәм кулланучылар хокукларын яклау буенча дәүләт инспекциясе, Татарстан Республикасы Президенты Аппараты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты, Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты, Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты, Татарстан Республикасының Мәдәни мирас объектларын саклау комитеты.

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| 3. | Гамәлгә куючы | |
| 4. | Милек формасы[4] | |
| 5. | Оешманың тибы[5] | |
| 6. | Адресы[6] | |
| | индекс | |
| | торак пунктның исеме | |
| | урам | |
| | йорт | |
| | йорт номеры | |
| 7. | Бюджет дәрәҗәсе[7] | |
| 8. | Бюджет классификациясе коды | |
| 9. | Салым түләүченең тәңгәлләштерү номеры (ИНН) | |
| 10. | Исәпкә кую сәбәбе коды (КПП) | |
| 11. | Административ-территориаль бүленеш объектларының гомумроссия классификаторы (ОКАТО) | |
| 12. | Хезмәт күрсәтү белән тәэмин итүченең исеме: | |
| | су белән тәэмин итү (сууткәргеч) | |
| | су чыгару (үзәкләштерелгән канализация) | |
| | чүп чыгару | |
| | кайнар су белән тәэмин итү | |
| | сыек көнкүреш калдыклары (чүп-чар чокыры) | |
| | җылылык (су) | |
| | электр энергиясе | |

Гомуми мәгълүматларны бирү нигезе: оештыру, үзгәртеп оештыру, тибын үзгәртү юлы белән оештыру (кирәклесе астына сызарга).

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органының / җирле үзидарә органының оештыру, үзгәртеп оештыру, тибын үзгәртү юлы белән оештыру турындагы __________ елның __________________ _________ номерлы ____________ ______________________________________________________________________ карары (күчермәсе теркәлә).

[4]Дәүләт, муниципаль.

[5]Автоном, бюджет, казна.

[6]Кемнең гомуми мәгълүматлары рәсмиләштерелүенә карап, юридик затның адресы яки юридик затның аерымланган структур бүлекчәсе адресы күрсәтелә.

[7]Татарстан Республикасы; муниципаль район, шәһәр округы; җирлекләр бюджеты.

Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль оешмалары күрсәтә торган дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләрне планлаштыру һәм мониторинглау буенча мәгълүмат ресурсын формалаштыруның бердәм ведомствоара системасында урнаштырыла торган дәүләт оешмалары һәм муниципаль оешмалар, шулай ук муниципаль берәмлекләрнең тышкы төзекләндерү объектлары тасвирнамәләрен мониторинглау һәм аларның алып барылышын тәэмин итү тәртибе турындагы нигезләмәгә
4 нче кушымта

1 нче таблица

Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль оешмалары күрсәтә торган дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләрне планлаштыру һәм мониторинглау буенча мәгълүмат ресурсын формалаштыруның бердәм ведомствоара системасында урнаштырыла торган дәүләт оешмалары һәм муниципаль оешмалар, шулай ук муниципаль берәмлекләрнең тышкы төзекләндерү объектлары тасвирнамәләре

| Т/с | Тышкы төзекләндерү объекты төренең исеме | Тасвирнамә исеме | Үлчәү берәмлеге |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | Юл хуҗалыгы | камилләштерелгән (асфальт-бетон) өслекле юлларның гомуми мәйданы һәм озынлыгы | километр / мең кв.метр |
| | | вак таш һәм таш өслекле юлларның гомуми мәйданы һәм озынлыгы | километр / мең кв.метр |
| | | тротуарларның гомуми мәйданы | мең кв.метр |
| 2. | Күпер хуҗалыгы | күперләр, юлүткәргечләр, тоннельләрнең гомуми мәйданы | кв.метр |
| 3. | Су саклау зоналары | гомуми мәйданы | гектары |
| 4. | Гидротехник корылмалар | ныгытылган ярларның һәм ясалма утыртмалары булган дамбаларның гомуми озынлыгы | пог.метр |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | | ныгытылган ярларның һәм ясалма утыртмалары булмаган дамбаларның гомуми озынлыгы | пог.метр |
| | | буаларның гомуми озынлыгы | пог.метр |
| 5. | Урам яктырткычлар | яктыртылган урамнар, машина юллары һәм яр буйларының гомуми озынлыгы | километр |
| 6. | Зират | зиратлар, үләт базлары, биотермик чокырларның гомуми мәйданы | гектары |
| 7. | Яңгыр канализациясе | гомуми озынлыгы | пог.метр |
| 8. | Яшел утыртмалар | Тау бите буенча газоннарның һәм су сиптерү системасының гомуми мәйданы | кв.метр |
| | | урамнар һәм яр буйлары буйлап яшел массивларның гомуми озынлыгы | километр |
| 9. | Җәяүлеләрнең җир астыннан һәм җир өстеннән юл аша чыгу урыннары | җәяүлеләрнең җир астыннан һәм җир өстеннән юл аша чыгу урыннарының гомуми мәйданы (лифтсыз) | кв.метр |
| | | җәяүлеләрнең җир астыннан һәм җир өстеннән юл аша чыгу урыннарының гомуми мәйданы (лифт белән) | кв.метр |
| 10. | Парклар, скверлар (бульварлар) | гомуми мәйданы | кв.метр |
| 11. | Башка корылмалар (пляжлар, фонтаннар, һәйкәлләр һ.б.) | беренчел торгызу кыйммәте | мең сум |

2 нче таблица

Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль оешмалары күрсәтә торган дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләрне планлаштыру һәм мониторинглау буенча мәгълүмат ресурсын формалаштыруның бердәм ведомствоара системасында урнаштырыла торган дәүләт оешмалары һәм муниципаль оешмалар, шулай ук муниципаль берәмлекләрнең тышкы төзекләндерү объектлары тасвирнамәләре турындагы мәгълүматның дөреслеген раслый торган документлар исемлеге

| Т/с | Документның төре | Документны рәсмиләштерү шартлары | |
|---|---|---|---|
| | | тышкы төзекләндерү объектлары буенча (гомуми файдаланудагы юллардан һәм юллардагы объектлардан башка) | гомуми файдаланудагы автомобиль юллары һәм юллардагы объектлар буенча |
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | Муниципаль мөлкәт реестрыннан өземтә | Россия Федерациясе Икътисадый үсеш һәм сәүдә министрлыгының «Федераль мөлкәт реестрыннан өземтә формасын раслау турында» 2007 елның 11 сентябрендәге 306 номерлы боерыгы нигезендә рәсмиләштерелә, финанс-бюджет палатасы, җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палаталары җитәкчеләре тарафыннан билгеләнгән тәртиптә таныклана | Россия Федерациясе Икътисадый үсеш һәм сәүдә министрлыгының «Федераль мөлкәт реестрыннан өземтә формасын раслау турында» 2007 елның 11 сентябрендәге 306 номерлы боерыгы нигезендә рәсмиләштерелә, билгеләнгән тәртиптә таныклана һәм ул гомуми файдаланудагы автомобиль юллары һәм алардагы объектлар турында түбәндәге мәгълүматны үз эченә ала:<br>реестр номеры;<br>хокукның төрен күрсәтеп, хокук иясе турында мәгълүматлар;<br>реестрга кертү датасы;<br>муниципаль берәмлекне, торак пунктны күрсәтеп, юлның (юлдагы объектның) урнашу урыны һәм исеме;<br>юлның (юлдагы объект- |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | | | ның) яисә объект урнашкан юлның тәңгәлләштерү номеры;<br>юл категориясе;<br>өслекнең төрен күрсәтеп, юл участокларының (юлдагы объектның) озынлыгы километрларда;<br>өслекнең төрен күрсәтеп, юл участокларының (юлдагы объектның) мәйданы мең кв.метрда |
| 2. | Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрыннан өземтә яки хокукны дәүләт теркәвенә алу турында таныклык | документта тышкы төзекләндерү объектларының техник тасвирнамәләре булганда | документта гомуми файдаланудагы автомобиль юлларының һәм һәм алардагы объектларның техник тасвирнамәләре (мәйданы, озынлыгы, өслекнең төре) булганда |
| 3. | Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрыннан өземтә яки хокукны дәүләт теркәвенә алу турында таныклык һәм һәм техник паспорт /план | Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрыннан өземтәдә яки хокукларны дәүләт теркәвенә алу турындагы таныклыкта тышкы төзекләндерү объектларының техник тасвирнамәләре булмаганда | Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрыннан өземтәдә яки хокукларны дәүләт теркәвенә алу турындагы таныклыкта гомуми файдаланудагы автомобиль юлларының һәм алардагы объектларның техник тасвирнамәләре (мәйданы, озынлыгы, өслекнең төре) булмаганда |
| 4. | Техник паспорт / план | – | хокук төрен мәҗбүри тәртиптә күрсәтеп, документта гомуми файдаланудагы автомобиль юлларының һәм алардагы объектларның техник тасвирнамәләре (мәйданы, озынлыгы, өслекнең төре) булганда |
| 5. | Милеккә кабул итү-тапшыру акты | тышкы төзекләндерү объектларының техник тасвирнамәләре булганда | юллар һәм объектлар яктылыгында гомуми файдаланудагы автомобиль |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | | | юлларының һәм алардагы объектларның техник тасвирнамәләре (мәйданы, озынлыгы, өслекнең төре) булганда |
| 6. | Электр энергиясен тапшыру буенча хезмәтләр күрсәтүче челтәр оешмасының белешмә кәгазе | «Урам яктырткычы» объектының төре буенча (яктырту челтәрләренең озынлыгы, баганалар һәм яктырткычлар саны турындагы мәгълүматны үз эченә ала) | – |